КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 21 июль г.Казань № 536

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турында» 2003 ел, 28 гыйнвар, 55 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе структурасын раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 11 март, 186 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче, 2013 ел, 20 апрель, 272 нче, 2013 ел, 3 июль, 468 нче, 2017 ел, 2 август, 539 нчы, 2018 ел, 27 июнь, 521 нче, 2019 ел, 23 ноябрь, 1070 нче, 2021 ел, 24 май, 363 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе структурасына, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт торак күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 сентябрь, 759 нчы, 2013 ел, 20 апрель, 272 нче, 2013 ел, 3 июль, 468 нче, 2013 ел, 18 декабрь, 1002 нче, 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче, 2016 ел, 16 сентябрь, 647 нче, 2017 ел, 2 август, 539 нчы, 2018 ел, 11 гыйнвар, 2 нче, 2018 ел, 9 апрель, 218 нче, 2018 ел, 24 август, 706 нчы, 2018 ел, 4 октябрь, 904 нче, 2018 ел, 23 ноябрь, 1041 нче, 2019 ел, 22 гыйнвар, 31 нче, 2019 ел, 21 июнь, 506 нчы, 2019 ел, 12 июль, 569 нчы, 2020 ел, 12 март, 185 нче, 2020 ел, 18 апрель, 305 нче, 2020 ел, 28 август, 750 нче, 2020 ел, 11 сентябрь, 824 нче, 2022 ел, 13 август, 809 нчы, 2023 ел, 4 февраль, 104 нче, 2023 ел, 7 июль, 795 нче, 2023 ел, 01 август, 916 нчы, 2023 ел, 16 декабрь, 1629 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Инспекциянең, аның структур бүлекчәләре булган районара торак инспекцияләре рәвешендә территориаль органнары һәм үзәк территориаль инспекторлык идарәсе бар:

Әлмәт районара торак инспекциясе;

Яр Чаллы районара торак инспекциясе;

Түбән Кама районара торак инспекциясе;

үзәк территориаль инспекторлык идарәсе.

Инспекция карамагында әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт торак (контроль) күзәтчелеге һәм төбәк дәүләт лицензия контроле функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлкәсендә Инспекция эшчәнлеген оештыру-техник, методик, мәгълүмати һәм эксперт белән тәэмин итү өчен дәүләт казна учреждениесе бар.

5.1 пунктта:

өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Районара торак инспекцияләре һәм үзәк территориаль инспекторлык идарәсе башлыклары Инспекция башлыгы тарафыннан үз вазыйфасына билгеләнеп куела һәм вазыйфасыннан азат ителә.»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Районара торак инспекцияләре һәм үзәк территориаль инспекторлык идарәсе башлыклары Татарстан Республикасының шәһәрләр, районнар буенча баш дәүләт торак инспекторлары булып тора.

Районара торак инспекцияләре һәм үзәк территориаль инспекторлык идарәсе башлыкларының урынбасарлары Татарстан Республикасының шәһәрләр, районнар буенча баш дәүләт торак инспекторларының урынбасарлары була.»;

5.2 пунктта:

унынчы абзацта «һәм шәһәр торак инспекцияләре» сүзләрен «торак инспекцияләре һәм үзәк территориаль инспекторлык идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацта «һәм шәһәр торак инспекцияләре» сүзләрен «торак инспекцияләре һәм үзәк территориаль инспекторлык идарәсе» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 936 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, 179 нчы, 2022 ел, 13 август, 810 нчы, 2023 ел, 22 сентябрь, 1176 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) районара торак инспекцияләре һәм үзәк территориаль инспекторлык идарәсе башлыклары - Татарстан Республикасының шәһәрләр, районнар буенча баш дәүләт торак инспекторлары;»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт торак күзәтчелеге кысаларында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар - Инспекция башлыгы (башлык урынбасарлары), районара торак инспекцияләре һәм үзәк территориаль инспекторлык идарәсе башлыклары (башлык урынбасарлары) була.»;

26 пунктның унберенче абзацында «Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына)» сүзләрен «вәкаләтле вазыйфаи затка» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 939 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 декабрь, 1276 нчы, 2022 ел, 22 июль, 713 нче, 2023 ел, 25 август, 1019 нчы, 2023 ел, 6 октябрь, 1255 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга төбәк дәүләт лицензия контроле турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) районара торак инспекцияләре һәм үзәк территориаль инспекторлык идарәсе башлыклары - Татарстан Республикасының шәһәрләр, районнар буенча баш дәүләт торак инспекторлары;»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт лицензия контроле кысаларында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрү турында карарлар кабул итүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар - Инспекция башлыгы (башлык урынбасарлары), районара торак инспекцияләре һәм үзәк территориаль инспекторлык идарәсе башлыклары (башлык урынбасарлары) була.»;

26 пунктның тугызынчы абзацында «Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына)» сүзләрен «вәкаләтле вазыйфаи затка» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 11 март, 186 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 21 июль, 536 нчы карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе структурасы

